*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№1 (48)

**Октябрь, 2022 нче ел**

***Хәерле сәгатьтә!***

*Сөенечләргә бай чор бит ул – яңа уку елы. Безгә «бишлеләр», уңышлар, җиңүләр алып килә торган бик тә нәтиҗәле вакыт. Өстәвенә, без мәктәптә әллә никадәр дуслар табабыз, укытучылар белән аралышырга, үзебез турында уңай фикер тудырырга, бик күп эш-мәшәкатьләр арасыннан иң-иң мөһимнәрен сайлап алырга өйрәнәбез.*

**Бу санда**

*Бариева Илина - ел укучысы!* 2

*Бәйгеләр, конкурслар, җиңүләр* 2

*Хәтерлим мин әле бүгенгедәй...* 3

*Сезнең алда без баш иябез...* 4

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Гимназия йолдызлары



Ел саен Республика көнендә “Хезмәткә – дан” Мактау тактасы яңартыла. 2022 елгы лаеклылар арасында гимназия укучылары да урын алды.

Бариева Илина - “Ел укучысы – 2022” титул иясе, биология, экология, химия фәннәреннән республика, бөтенроссия олимпиадалары җиңүчесе, Татарстан һәм Россия күләмендә узган армрестлинг ярышлары буенча чемпион.

Баянов Шамил - район тарихында тәүге тапкыр химия һәм биология фәннәреннән бердәм дәүләт имтиханнарында 200 балл җыючы буларак Россиянең иң яхшы укучылары исемлегенә кертелде.

### Үз эшенең остасы



Гимназиянең биология укытучысы Бариева Ләйсән Фәхәметдин кызы Казан шәһәрендә узган Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына педагогик эшчәнлектәге уңышлары өчен премия бирү бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләү тантанасында катнашты һәм хөрмәтләнде. Ләйсән Фәхәметдиновнаны зур нәтиҗәләргә ирешүе белән котлыйбыз, иҗади уңышлар телибез!

### TATAR HACK цифрлы проектлар эшләү бәйгесе



Гимназия базасында цифрлаштыру елы кысаларында TATAR HACK цифрлы проектлар эшләү буенча республика конкурсының чираттагы этабы узды. Чарада районыбызның мәктәпләреннән барлыгы 10 команда катнашты. Укучылар IT технологияләр ярдәмендә мәгариф, туризм һәм спорт өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү буенча проектлар уйлап таптылар. Иң яхшы проектлар исемлегендә гимназия укучылары да бар. Афәрин, егет-кызлар!

### Ризаэддин Фәхреддин исемендәге Республика премиясе



Казан шәһәренең “Адымнар” полилингваль комплексында “Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү” республикакүләм форумы узды. Аның кысаларында Каюм Насыйри һәм Ризаэддин Фәхреддин исемендәге республика премияләренә йомгак ясалды. Мөслим гимназиясе коллективына укыту һәм тәрбия өлкәсендә ирешкән уңышлары өчен Ризаэддин Фәхреддин исемендәге Республика премиясе тапшырылды.

# БАРИЕВА ИЛИНА - ЕЛ УКУЧЫСЫ

## *Укырга, эзләнергә, табарга!*

«Тылсым+» түгәрәгенә йөрүче балалар “Ел укучысы – 2022” титулына лаек булган 10 нчы сыйныф укучысы Бариева Илина белән очрашып, берничә сорау белән мөрәҗәгать иттеләр.



Районкүләм «Ел укучысы - 2022» исеменә лаек булган 10 нчы сыйныф укучысы Бариева Илина Казан шәһәрендә «Ел укучысы - 2022» бәйгесенең республика этабында катнашты. Илина "Ел интеллекты" номинациясендә җиңү яулады.




10 нчы октябрьдән 15 нче октябрьгә кадәр Ульяновск шәһәрендә "Ел укучысы - 2022" Бөтенроссия конкурсының федераль этабы узды, анда Илина "Ел интеллекты" номинациясендә Татарстан Республикасын тәкъдим итте.

Конкурсның төп максаты белем бирү оешмалары өчен бердәм аралашу тирәлеген булдыру һәм тәҗрибә уртаклашу, аларның казанышларына һәм талантларына ярдәм итү. Финалда Россиянең 42 төбәгеннән 150 өлкән сыйныф укучысы катнашты Бу титул өчен илнең барлык төбәкләренең иң лаеклылары көрәште. Илина катнашучы дипломы белән бүләкләнеп, зур тәҗрибә туплап, күп дуслар табып кайтты.

***Илина, Ульяновск шәһәреннән нинди хис-кичерешләр белән кайттың?***

Ульяновскида «Ел укучысы - 2022» Бөтенроссия конкурсының финал этабында катнаштым. Анда үземнең проектымны уңышлы гына якладым. Миңа барсы да бик ошады. Күп дуслар таптым.

Ульяновск бик матур борынгы шәһәр. Ульянов-Ленин шушы калада яшәгән, университетта укыган. Советлар Союзына (гәрчә мин ул вакытларны белмәсәм дә) кайтып килгән кебек буласың.

“Ел укучысы – 2022” конкурсы Ленин укыган, хәзер аның исемен йөрткән Ульяновск дәүләт педагогика университетында үтте. Күңелдә әйтеп, аңлатып бетерә алмый торган халәт барлыкка килде. Горурлык хисе туды.

***Үзең кебек яшьләр белән аралашу сиңа нәрсә бирде?***

Конкурска килгән яшьтәшләрем-катнашучылар белән аралашу миңа, үземдә булмаган сыйфатларны булдырырга кирәклеген аңларга ярдәм итте.

***Вакыт машинасы булса, кайсы шәһәр һәм чорга сәяхәт итәр идең?***

Сочига, Сириуска. Кайсы чор булса да.

***Киләчәктә нинди һөнәр сайларга уйлыйсың?***

Казан дәүләт медицина университетына укырга керәсем килә. Хыялым табиб булу.

***Гимназия укучыларына әйтер сүзләрең бармы?***

Иң беренче вакытны дөрес бүлә белергә кирәк. Тырышып укырга, укырга һәм укырга! Спорт белән шөгыльләнергә! Үз өстеңдә даими эшләп торырга. Шул ук вакытта дусларың белән аралашырга да вакыт табарга. Аның өчен барлык мөмкинлекләр дә булдырылган.

Рәхмәтләремне гимназия коллективына, укытучыларыма, сыйныф җитәкчем Гөлшат Ильясовнага, ныклы таянычым булган гаиләмә җиткерәсем килә.

# БӘЙГЕЛӘР, КОНКУРСЛАР, ҖИҢҮЛӘР

## Мөслим кызы 2022



10 нчы сыйныф укучысы Камилә Минһаҗева "Мөслим кызы - 2022” титулына лаек булды. Шулай ук Камиләбез укучы кызлар арасында бишенче мәртәбә үтүче Бөтенроссия "Ак калфак" бәйгесендә катнашты.

## "Шаян ТВ" каналында кунакта



10 нчы сыйныф укучылары Бариева Илина, Минһаҗева Камилә Казан шәһәренә барып, “Шаян ТВ” каналында үзләренең уңышлары белән уртаклашып, интервьюла бирделәр.


## Илзирә "АгроНТИ - 2022" финалисты



Бөтенроссия АгроНТИ - 2022 конкурсының «Игелекле умарта корты» юнәлешендә 7 нче а сыйныфы укучысы Зиннурова Илзирә өченче урынга лаек булды. Укытучысы Бариева Л.Ф.

# ХӘТЕРЛИМ ӘЛЕ МИН БҮГЕНГЕДӘЙ...

***Укытучы, мәктәп... Гомер узган саен бу сүзләрне гел искә төшерәбез. Шушы сүзләрне ишеткән саен, балачакка, мәктәп елларына кире әйләнеп кайткан кебек булабыз. Нәкъ җырдагыча, хәтерлим мин әле бүгенгедәй…***










## 11 класс укучыларының укытучыларга багышлап язган иншалары

### Рәхмәт сиңа, укытучым!

Иң беренче мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып, зур тормышка озатып, соңгы кыңгырау чыңлаган көнгә кадәр безнең янәшәбездә һәрчак яраткан укытучыларыбыз атлый. Алар безне белем дөньясына алып керә, яхшыны яманнан аерырга, хезмәтне яратырга өйрәтә.

Әле яңа гына 1 нче сыйныфка кергән кебек тоелса да унберенче сыйныфка җиткәнбез. Хәреф танырга, укырга-язарга, санарга өйрәткән беренче укытучыбыз Гөлчәчәк Фирдәвис кызының яңгыравыклы тавышы колак төбендә чыңлап тора. Хәзерге сыйныф җитәкчесе Ләйсән Фәхәметдиновна төгәл, принципиаль, таләпчән булуы белән үзенә җәлеп итә.

Безнең гимназиядә укытучылар иң яхшылары, иң кешелеклеләре. Директорыбыз Азат Фәрит улы - дирижер. Завучлар: Лира Нурфаяз кызы расписаниены җайлый, көйли, һәр дәрес өчен борчыла. Лилиана Расиховна матур итеп елмаеп грамоталар тапшыра, безнең ирешкән уңышларга сөенә, янып-көеп проектлар эшләргә өйрәтә. Тәрбия өлкәсендә “наполеонский” планнар корып йөрүче, үзенчәлекле тәрбия ысуллары белән аерылып торучы Гөлнара Фердинандовнага тиңнәр юк. Ә гимназиянең “полициясе” Миләүшә Рөстәмовнага эләксәң бетте баш... Аеруча тәртипсезлек кылырга яратучы малайларга кыенга туры килә.

Безне укыткан мөгаллимнәребез безнең барлык шаянлыкларны да кичерә, белемгә омтылыш уяту өчен төрле яңа алымнар кулланып дәресләр үткәрә, төн йокыларын калдырып дәфтәрләр тикшерә. Укытучыларыбызның сабырлыгына, фидакарьлегенә, тырышлыгына, булдыклыгына таң калырлык.

***Солтанова Алия***

### Минем яраткан укытучым.

Чын укытучы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш соң? Ул, әлбәттә, эш сөючәнлек, тырышлык, балалар белән эшли белү һәм иң мөһиме - үз фәнеңне сөю. Бу сыйфатларның барысына да ия булган укытучы гимназиябездә эшли. Ул - Бариева Ләйсән Фәхәметдин кызы - минем класс җитәкчесе һәм биология укытучысы.

Ләйсән Фәхәметдин кызы чыннан да үз эшенең остасы. Аның белән бергә без мәктәп тормышындагы һәрбер эштә бик актив катнашабыз. Ул һәрвакыт безгә үрнәк булып тора. Бездән чын шәхес тәрбияләүгә бөтен көчен бирә, дөрес итеп фикерләргә, югары дәрәҗәләргә ирешергә өйрәтә.

Мин укытучымны бик яратам һәм хөрмәт итәм!

***Фатхуллина Эльвина***

***

Кешенең иң матур, иң татлы һәм җылы истәлекләре аның балачагы белән бәйләнгән була. Иң күңелле хатирәләр, әлбәттә мәктәп еллары. Мәктәп дигәч, күз алдына шунда ук укытучы килеп баса.

Минем үземнең беренче укытучым турында сөйләп китәсем килә. Ул - Гөлчәчәк Фирдависовна. Аның безне беренче тапкыр каршы алуы бүгенгедәй хәтеремдә. Ул безне бик күпкә өйрәтте. Яхшыны яманнан аерырга да, хезмәт һәм иҗат шатлыгын тоярга да. Бездән чын шәхес тәрбияләргә бөтен көчен бирде.

Укытучы булу җиңел түгел. Ул зур сабырлык, балаларга карата олы мәхәббәт һәм сайлаган һөнәргә карата чиксез бирелгәнлек таләп итә.

Мин беренче укытучымны бик яратам һәм хөрмәт итәм.

Гөлчәчәк Фирдависовнага авыр һәм мактаулы эшендә зур уңышлар телим.

***Харисов Илназ***

Һәр кеше мәктәп юлларын үткән. Һәм бөтен кешенең дә, минем уйлавымча, яраткан укытучысы булгандыр. Минем өчен ул Саяхова Зөлфирә Мөхәр кызы.

Зөлфирә Мөхәровна бик гадел, түземле, яхшы укытучы. Аның алымнары мавыктыргыч. Ул безгә физикадан авыр темаларны да җиңел һәм аңлаешлы итеп аңлата.

Зөлфирә Мөхәровна, сезгә мин бик рәхмәтле! Алдагы көннәрегездә бәхет, шатлык, озын гомер телим.

***Шәйхиев Раил***

> *«Боекмас өчен күңелләр, кимсенмәс өчен йөрәк – сез кирәк, укытучылар, безгә һәрчак сез кирәк!»*

Һәр укытучы да хөрмәткә, укучы мәхәббәтенә лаек. Ләкин шулай да күңелгә иң якын булган укытучылар бар. Алар мәңгелеккә күңелдә кала торган кешеләр.

Минем дә яраткан һәм хөрмәт иткән укытучыларым бар. Шулар арасыннан аеруча иң якыннары - минем сыйныф җитәкчем, биология укытучысы – Ләйсән Фәхәметдин кызы һәм химия укытучысы Венера Гайсә кызы.

Ике яраткан укытучым да үз фәненең осталары. Аларның һәр дәресе мавыктыргыч. Үзләренең таләпчәнлекләре өчен укучылары да белемле. Шулай ук алар белән һәрвакыт серләшәсе, күңелдәгене сөйлисе килеп тора. Һәр көн мәктәпкә кутәренке кәеф белән баруның сәбәпчеләре дә алар.

***Шәйхиева Динара***

***

Минем яраткан укытучым – Гөлназ Рәис кызы. Ул мине инглиз теленә өйрәтте. Һәр дәресне мин түземсезлек белән көттем. Яңа сүзләрне, яңа кагыйдәләрне бик кызык итеп аңлата иде ул. Гөлназ Рәисовнаның биргән белемнәрен мин хәзер дә кулланам.

Гөлназ Рәисовнага сәламәтлек, эшендә уңышлар, тәрбияле укучылар теләп калам.

***Исмәгыйлова Лиана***

# СЕЗНЕҢ АЛДА БЕЗ БАШ ИЯБЕЗ...

**Октябрь ае бик күркәм бәйрәм – Өлкәннәр көне белән башланып китә, Укытучылар көне белән дәвам итә. Өлкәннәр!.. Олы кешеләр!..** Күпме мәгънә табып була бу сүзләрдән. Элек-электән үк олы кешеләр тормышның, яшәешнең нигезен тәшкил иткәннәр. Шуңа күрәдәдер инде, безнең əти-əниләребез зур кешеләрнең сүзен тыңлагыз, аларның әйткәннәренә колак салыгыз дип өйрәттеләр. Чыннан да, алар киңәшче дә, якын дус та, ярдәмче дә һәм иң мөһиме, акыл бирүчеләр дә.

Өлкәннәр һәм Укытучылар көне уңаеннан, Мөслим гимназиясендә бик матур чаралар узды. Башлангыч сыйныф укытучылары, үзләренең 4 дистәдән артык елларын балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган, ветеран укытучыларыбыз өчен "Сезнең алда без баш иябез" дип исемләнгән әдәби-музыкаль чара үткәрделәр.

Чарабызга килгән Петрова Надежда Николаевна үзенең гаиләсенең укытучылар династиясе булуы турында сөйләде. Гимназиягә быел беренче сыйныфка кергән оныкчыгы Риананың да укытучы булачагына өметләнә ул. Надежда Николаевна укучыларыбызга һәм укытучыларыбызга үзенең изге матур теләкләрен җиткерде. Хәтирәләре белән уртаклашканда, күз яшьләре аша елмаеп, ул үзенең бәхетле әни, кадерле әби һәм якын әбекәй икәнен исбатлады.

Мәгариф системасы соңгы дистә еллар эчендә бик күп үзгәрешләр кичерде. Яңа федераль стандартлар кергәч, электрон журнал, электрон дневник, электрон документация-ләр барлыкка килде. Бу чорда эшләгән кешеләргә шактый гына авырлыклар күрергә туры килде. Идиатуллина Маргарита Александровна менә шундый ничә буын үзгәрешләрен күргән педагог. Ана куелган сорау да шулайрак яңгырады. Әлбәттә, үз эшенең асылын белгән, җаны-тәне белән һөнәренә тугъры калган укытучы, бу баскычларны бик җиңел узуы турында әйтте. "Мәктәпне, укучыларны, укытучыларны бик сагынам, ләкин тыныч картлыгымда, сезнең уңышларга сөенеп, өйдә утыруны кулайрак күрәм," - диде ул, фикерен йомгаклап. Маргарита Александровнада әле һаман да эшләү дәрте сүрелмәгәнлеген сиземләдек. Укучыларыбызның һәр чыгышын телефонына төшереп утыруы, аларга соклануын яшерә алмыйча, эчкерсез елмаю – моның ачык мисалы булды.

Мөслим гимназиясендә озынайтылган көн группасында эшләгән Нигимаева Гүзәлия Әнвәр кызы, безнең тарафтан бирелгән сорауны ишеткәч, югалып калды. "Хәтеремдә калган кызыклы вакыйгалар, гел башымнан чыгып бетте шул," – дип көлде ул. Бераз утырганнан соң, үзе белән, укучылар белән




булган кызыклы хәтирәләрен бик тәмләп сөйләде.

Һәр лаеклы ялдагы укытучы үзенчә бәхетле, үзенчә серле иде бу көнне. Чөнки ничә еллар буена укытучы булып эшләү, аларның берсенә дә ансат кына бирелмәгәндер. Ә без, яшь буын, алар алдында, баш иябез, алар үрнәгендә, балаларга белем һәм тәрбия бирергә омтылабыз. Ләкин, бүген замана башка, дөньяга караш башка, балаларның уйлау-фикерләү формасы башка... Былтыргы "А", быел да шул ук "А" булса да, яңгырашы үзгә.

Киләчәктә дә матур бәйрәмнәрдә очрашып, буыннар чылбырын өзмичә, бәхетле тыныч тормышларда яшәргә язсын.

***Миләүшә Хәсәнова,***
***Мөслим гимназиясенең***
***башлангыч сыйныфлар***
***укытучысы***



**Тормыш дәресләре**



**Әлкәннәребезне котлау**

ТЫЛСЫМ+

Октябрь, 2022 нче ел

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Мингазова Камилә

**Корректорлар:** Мингазова Диләрә

**Корреспондентлар:** Айгельдина Зәринә, Султанова Алия

**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыпов Илназ, Хаертдинов Ранис
**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Тираж**: 100